КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 26 февраль г.Казань № 94

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Хроник бөер эшчәнлеге җитешсезлеге белән интегүче, амбулатор гемодиализ ысулы белән дәвалану алучы затларга амбулатор гемодиализ үтү урынына транспортта бару һәм яшәү урынына кире кайту чыгымнарын һәм онкология авырулары белән интегүче затларга махсуслаштырылган онкология ярдәме күрсәтүче Татарстан Республикасы дәүләт сәламәтлек саклау системасының медицина оешмаларына дәвалану урынына транспортта бару һәм яшәү урынына кире кайту чыгымнарын компенсацияләү тәртибен раслау турында» 2013 ел, 9 октябрь, 743 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Хроник бөер эшчәнлеге җитешсезлеге белән интегүче, амбулатор гемодиализ ысулы белән дәвалану алучы затларга амбулатор гемодиализ үтү урынына транспортта бару һәм яшәү урынына кире кайту чыгымнарын һәм онкология авырулары белән интегүче затларга махсуслаштырылган онкология ярдәме күрсәтүче Татарстан Республикасы дәүләт сәламәтлек саклау системасының медицина оешмаларына дәвалану урынына транспортта бару һәм яшәү урынына кире кайту чыгымнарын компенсацияләү тәртибен раслау турында» 2013 ел, 9 октябрь, 743 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 ел, 10 май, 312 нче, 2014 ел, 30 сентябрь, 696 нчы, 2019 ел, 1 ноябрь, 996 нчы, 2020 ел, 16 декабрь, 1141 нче,

2022 ел, 30 декабрь, 1479 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләре исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

преамбулада «8.1 һәм 8.2 статьялар» сүзләрен «8.1 статья» сүзләренә алмаштырырга;

түбәндәге эчтәлекле 42 пункт өстәргә:

«$4^2$. Татарстан Республикасы муниципаль районнарында (шәһәр округларында) «Республика матди ярдәм (компенсация түләүләре) үзәге» дәүләт казна учреждениесе бүлекчәләре гарызнамәләре буенча Татарстан Республикасы муниципаль районнарының җирле үзидарә органнарына хроник бөер җитешсезлеге белән интегүче затларның һәм онкология авырулары белән интегүче затларның яшәү урыныннан Татарстан Республикасы муниципаль районы җирле администрациясе урнашкан урынга кадәр ераклыгы турында мәгълүмат бирүне тәкъдим итәргә.»;

әлеге карар белән расланган Хроник бөер эшчәнлеге җитешсезлеге белән интегүче, амбулатор гемодиализ ысулы белән дәвалану алучы затларга амбулатор гемодиализ үтү урынына транспортта бару һәм яшәү урынына кире кайту чыгымнарын һәм онкология авырулары белән интегүче затларга махсуслаштырылган онкология ярдәме күрсәтүче Татарстан Республикасы дәүләт сәламәтлек саклау системасының медицина оешмаларына дәвалану урынына транспортта бару һәм яшәү урынына кире кайту чыгымнарына компенсация билгеләү тәртибендә:

2 һәм 3 пунктлар үз көчләрен югалткан дип танырга;

5 һәм 6 пунктларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. Компенсация күләме түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$K = 2 \times T \times (R_1 + R_2) + 2 \times C,$$

монда:

K - компенсация күләме;

T - Татарстан Республикасы территориясендә җайга салынмый торган тарифлар буенча даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципальара маршрутларында бер километр арага баруның уртача бәясе;

$R_1$ - мөрәҗәгать итүченең яшәү урыныннан мөрәҗәгать итүче яшәгән Татарстан Республикасы муниципаль районының җирле администрациясе урнашкан урынга кадәр ераклык;

$R_2$ - мөрәҗәгать итүче яшәгән Татарстан Республикасы муниципаль районының (шәһәр округының) җирле администрациясе урнашкан урыннан медицина оешмасы урнашкан Татарстан Республикасы муниципаль районының (шәһәр округының) җирле администрациясе урнашкан урынга кадәр ераклык;

C - Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитеты тарафыннан билгеләнгән банк хисабы аша билет алганда медицина оешмасы урнашкан Татарстан Республикасы муниципаль берәмлегендә даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципаль маршрутлары буенча автомобиль транспортында һәм шәһәр җир өсте электр транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртүнең иң чик максималь тарифы.

Дәвалау курсы бер көннән артык дәвам иткәндә компенсация исәпләгәндә күрсәтелгән дәвалану курсы узган урынга бару һәм яшәү урынына кире кайту исәпкә

алына (әлеге Тәртипнең 11 пунктының өченче абзацында күрсәтелгән документларны тапшырмаган очракта).

6. Мөрәҗәгать итүче юл документларын тапшырган очракта компенсация әлеге Тәртипнең 7 пунктында күрсәтелгән транспорт чарасында дәвалану урынына бару һәм яшәү урынына кайту өчен түләүгә факттагы чыгымнар күләмендә башкарыла.

Әлеге Тәртипнең 5 пункты нигезендә исәпләнгән компенсация күләмен яңадан исәпләү «Республика матди ярдәм (компенсация түләүләре) үзәге» дәүләт казна учреждениесенең муниципаль районындагы (шәһәр округындагы) (алга таба - Үзәк бүлеге) дәүләт казна учреждениесенең юл йөрү документларын тапшырганнан соң гамәлгә ашырыла.

«Дәүләт социаль ярдәме турында» 1999 елның 17 июлендәге 178-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә социаль хезмәтләр җыю кысаларында шәһәр яны тимер юл транспорты белән бушлай йөрү хокукына ия затларга шәһәр яны тимер юл транспорты буйлап бару чыгымнары компенсацияләнми.»;

8 пунктның беренче абзацында «әлеге пунктның икенче абзацында күрсәтелгән очрактан тыш» сүзләрен төшереп калдырырга;

9 пункт үз көчен югалткан дип танырга;

11 пунктның дүртенче, алтынчы - унынчы абзацлары үз көчен югалткан дип танырга;

12 пунктта:

икенче һәм өченче абзацларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«мөрәҗәгать итүченең яшәү урыныннан мөрәҗәгать итүче яшәгән Татарстан Республикасы муниципаль районының җирле администрациясе урнашкан урынга кадәр ераклык турында мәгълүмат;

гражданның амбулатор гемодиализ процедураларын узу датасы турында, гражданның махсуслаштырылган онкология ярдәме күрсәтүче медицина оешмасында дәвалану вакыты турында белешмәләр;»;

дүртенче абзац үз көчен югалткан дип танырга;

13 пункт үз көчен югалткан дип танырга;

14 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«14. Компенсация алу максатларында мөрәҗәгать итүчеләр, аларның законлы вәкилләре яисә Россия Федерациясе законнары нигезендә рәсмиләштерелгән ышанычнамә нигезендә вәкаләтле затлар үз инициативасы белән Үзәк бүлегенә әлеге Тәртипнең 12 пунктының өченче абзацында күрсәтелгән белешмәләрне раслаучы документларны тапшырырга хокуклы.

Әлеге пунктның беренче абзацында күрсәтелгән очракта компенсация әлеге Тәртипнең 12 пунктындагы өченче абзацында күрсәтелгән белешмәләрне раслый торган документлар тапшырылганда гамәлгә ашырыла.»;

17 пунктның икенче абзацында «(әлеге Тәртипнең 9 һәм 13 пунктларында күрсәтелгән очраклардан тыш)» сүзләрен төшереп калдырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин